АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«20» апрель 2026 ел** № 15

**«Татарстан Республикасының нвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында» Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 2016 елның 15 февралендәге № 13-2/2лс боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы № УП-569 Указы нигезендә,

БОЕРУ:

1. «Татарстан Республикасының нвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында» Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 2016 елның 15 февралендәге № 13-2/2лс боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 16.03.2018 № 5, 23.09.2022 № 52, 27.02.2023 № 4, 24.08.2023 № 27, 07.12.2023 № 48, 11.12.2024 № 44, 19.02.2026 № 9/2 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия Агентлыкның норматив хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.»;

2.2 нче пунктының «а» подпунктында:

«(Комиссия рәисе),» сүзләреннән соң «Агентлыкның хокукый һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы (Комиссия рәисе урынбасары),» сүзләрен өстәргә;

3.1 нче пунктының «а» подпунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләрне дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бирү турында»;

3.11 пунктының «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-№ 702 Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары Галиев Инсаф Мөшәррәф улына йөкләргә.

Җитәкче Т. И. Миңнуллина